РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«12» март 2020г. г. Альметьевск №359

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 11 мартындагы «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган турында»гы 286 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Балигъ булмаганнарга составында никотин булган башка продукцияне сатуны чикләү, никотинны илтеп җиткерүнең электрон системаларын һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертүне тыю турында» 2019 елның 25 декабрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2013 елның 11 мартындагы «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган турында»гы 286 нчы номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 252 нче номерлы, 2019 елның 26 июлендәге 309 нчы номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 пунктында «2.15» саннарыннан соң «2.16» саннарын естәргә.

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Зак. № 3775